ГЛАВА КОРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная площадь, д.1, с. Коргуза,
422586

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАРАГУЖА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 1 нче йорт, Карагуҗа авылы,
422586

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　КАРАР

31.10.2023　　　　с. Коргуза　　　　02

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлегенең Патрикеево  авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»  2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы  Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Уставының 24 статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының районының Карагуҗа авыл җирлегенең Патрикеево авылы гражданнары арасында 2023 елның 17 ноябренә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны  расларга: “Сез 2024 елда Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлегенең Патрикеево авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 800 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:
   - Патрикеево авылында Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәйкәл төзү, мемориаль такталар урнаштыру, һәйкәл территориясен койма белән әйләндереп алу

   «ӘЙЕ»　　　　　　　　　　«ЮК»
3. Патрикеево авылы, Яр буе урамы, 10 йорт адресы буенча урнашкан Патрикеево авыл клубы бинасында 13.00 сәгатьтә гражданнар җыенын үткәрергә.
4. Карагуҗа авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　Д.В.Плохов